# Сакаллы килеш туа, берәү дә гаҗәпләнми


IranSun.net

*

# Кош түгел, оча,
# Ябалактан курка,
# Чикләвекне ярата,
# Сызгырса, урманны яңрата.



Җәен соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак.



**Энәләре үзе белән йөри,**
**Үзе тегә белми.**


myJulia.Ru

**Нечкә билле,**
**көлтә**
**койрыклы.**



* Асрамый да умарта,
Балны бик-бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача тормый ята.



Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Сарыклар эзли.



**Аягын-башын ящерә**
**Таш күлмәге эченә.**



**Койрыгы озын,**
**Үзе кыска,**
**Мәчедән курка.**



**Тимерче дә түгел,**
**Балта остасы да түгел,**
**Үзе авылда беренче эшче.**




**Кешенең дусты, йортның сакчысы.**




Үзе җылыда,
Үзе тун ябынып
йоклый.


kissa

Канаты бар,
Аягы бар, –
Йөзә алмый.



**Йомры, йомшак**
**сары йомгак**
**Йөгереп йөри**
**чирәмдә.**



Суда йөзә,
Күктә оча,
Җирдә йөри.
Ит белән сыйлый.



- **Үлән ашый, сөт, май бирә.**

